**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 гыйнварындагы 73 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең балалар музыка, рәсем сәнгате, спорт, хореография мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә, югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Аеруча сәләтле балаларга ярдәм итү, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы балалар музыка, рәсем сәнгате һәм хореография мәктәпләре укучыларының мөмкинлекләрен киңәйтү һәм сәләтләрен гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең балалар музыка, рәсем сәнгате, спорт, хореография мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә, югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 3136 номерлы, 2022 елның 22 декабрендәге 4582 номерлы, 2024 елның 27 ноябрендәге 4897 номерлы, 2025 елның 9 октябрендәге 3401 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«1.2. Балалар музыка мәктәпләре, балалар сәнгать, рәсем сәнгате һәм хореография мәктәпләре укучылары өчен һәркайсы 25 000 сумлык 16 исемле стипендия булдырыла».

2. Әлеге карарның йогынтысы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**